ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2022 с.Старое Дрожжаное № 529

Аерым административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 07 апрелендәге 187 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую, яңадан теркәү һәм исәпкә алу эшенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, **2.6.1 пунктының 11 пунктчасында** «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 июнендәге 241 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, **2.6.1 пунктының 12, 17, 18 пунктчаларында** «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 гыйнварындагы 25 номерлы карары белән расланган Торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, **2.6.1 пунктының 10, 15, 17, 18 пунктчаларында** «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов